**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ**
**МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**

422750, село Большая Атня, улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**

422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы., 38нче йорт

Тел.: 8(84369)21004, факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

# КАРАР

03 февраль 2020 ел. № 7

Әтнә муниципаль районында эшләүче
һәм яшәүче аерым категория гражданнарга
торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча
социаль ярдәм чаралары турында

Әтнә муниципаль районында эшләүче һәм яшәүче муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренә социаль ярдәм чараларын күрсәтү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Авыл җирендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче аерым категория гражданнарга торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында» 2005 елның 20 апрелендәге 192 номерлы карары нигезендә, Әтнә муниципаль районы башлыгы карар бирә:

1. Муниципаль учреждениеләр белгечләренә, Әтнә муниципаль районында эшләүче һәм яшәүче педагогик хезмәткәрләргә, мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсе хезмәткәрләренә, Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән торак мәйданының социаль нормасы чикләрендә торак, газ, электр белән тәэмин итү, электр белән тәэмин итү өчен түләү чыгымнарының 100 проценты күләмендә социаль ярдәм чараларын бирүне билгеләргә. Күрсәтелгән социаль ярдәм чарасы, шулай ук, пенсиягә чыккан, авыл җирендә яшәүче һәм мәгариф оешмаларында, мәдәният учреждениеләрендә, кимендә 10 ел эшләгән күрсәтелгән хезмәткәрләргә дә бирелә;

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән гражданнарның аерым категорияләренә субсидияләр биргәндә «Авыл җирендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чараларын бирү тәртибен раслау турында»Татарстан Республикасы

Министрлар Кабинетының 2005 елның 7 июнендәге 251 номерлы карарына таянып эш итәргә.

3. Әтнә муниципаль районы Башлыгының «Әтнә муниципаль районында эшләүче һәм яшәүче аерым категория гражданнарга торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында» 2006 елның 20 декабрендәге 50 номерлы карары үз көчен югалткан дип санарга.

4. Финанс-бюджет палатасында Әтнә муниципаль районы бюджетында әлеге карарны гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджет ассигнованиеләре исәбеннән кирәкле акчалар карарга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әтнә районы башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Район Башлыгы Г.Г. Хәкимов